КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 2 март г.Казань № 153

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 сентябрь, 1197 нче; 2024 ел, 5 июль, 518 нче; 2025 ел, 3 ноябрь, 903 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Физик культура һәм спорт өлкәсендә хәзерге хәлне бәяләү

Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт тармагының хәзерге торышы Россия Федерациясе Президенты указлары һәм йөкләмәләре нигезендә физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен, «Физик культураны һәм спортны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы һәм «Демография»

илкүләм проектының «Спорт – яшәү нормасы» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру, 2014 елдан алып 2024 елга кадәр «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – дәүләт программасы) кысаларында эш йомгаклары булып тора һәм түбәндәге күрсәткечләр белән характерлана.

2024 ел нәтиҗәләре буенча физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче гражданнар өлеше, 2016 ел белән чагыштырганда, 15,6 проценттан 65,8 процентка кадәр артты. Инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында әлеге күрсәткеч, 2024 ел нәтиҗәләре буенча, 39,1 процент тәшкил итте (исәп-хисап физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә ярамый торган билгеләре булмаган инвалидлар санынннан чыгып ясалды).

Татарстан Республикасының физик культура чаралары һәм спорт чаралары буенча бердәм календарь план нигезендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан ел саен 800дән артык физик культура чарасы, шул исәптән балалар һәм укучы яшьләр арасында үткәрелә. 2013 елдан 2024 елга кадәр үткәрелә торган чаралар саны якынча 55 процентка артты.

2017 – 2024 елларда Татарстан Республикасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәү буенча 55 тест үткәрү үзәге һәм 385 тест үткәрү урыны булдырылды.

2024 елда спорт корылмаларының гомуми саны 12 000 берәмлеккә җитте, шул исәптән 5 090 объект – авыл җирлегендә, 3 024 объект – сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидлар өчен. 2024 елда бер тапкыр үткәрү сәләте күрсәткече 71,9 процентка җитте. Бу барлык спорт корылмаларында берьюлы 331 000 нән артык кеше шөгыльләнергә мөмкин дигәнне аңлата.

Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү системасын үстерү үткәрелә торган социаль сәясәтнең өстенлекле юнәлеше булып тора һәм ышанычлы норматив хокукый базага нигезләнә.

2025 елның 1 гыйнварына карата Татарстан Республикасында балалар һәм яшьүсмерләр спорты һәм спорт резервын әзерләү системасында 164 спорт мәктәбе эшли (шуларның 26 спорт мәктәбе олимпия резервы статусына ия).

Спорт мәктәпләрендә 79 спорт төре үстерелә, шуларның 46сы – олимпия спорт төрләре; 29ы – олимпия булмаган спорт төрләре; 4 төре – сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен.

5-ФК статистика хисабы нигезендә 91 207 тәрбияләнүче спорт әзерлеген үтә. Тәрбияләнүчеләр белән укыту-күнегүләр ясау эше 2 984 тренер-укытучы тарафыннан гамәлгә ашырыла, шуларның 2 311е – штатта эшли, 673е – берьюлы ике вазыйфа били.

Россия җыелма командалары составына Татарстан Республикасыннан 1 005 спортчы (2023 елда – 957) кертелгән, шуларның олимпия спорт төрләре буенча – 484 спортчы (2023 елда – 461).

Татарстан Республикасында югары дәрәҗәдә әһәмиятле спорт чаралары оештырылды һәм үткәрелде: 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиада, 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты, спортның су төрләре буенча, билбау көрәше

буенча, көрәш буенча, I БДБ илләре уеннары, «Дуслык уеннары» халыкара ярышлары.

2024 елда Татарстан Республикасы территориясендә 70тән артык зур спорт чарасы оештырылды, шуларның 12се халыкара дәрәҗәдә, иң әһәмиятлеләре: «Киләчәк уеннары» халыкара күптөрле спорт турниры (19 февраль – 3 март), анда 116 илдән 1 811 катнашучы 21 инновацион дисциплинада катнашты; «БРИКС илләре спорт уеннары» халыкара күптөрле спорт чарасы (12 – 23 июнь), анда 82 илдән 4 267 кеше катнашты.

Казан шәһәрендә әлеге проектларны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең халыкара аренада имиджын күтәрүгә һәм вакыйгалар туризмын үстерүгә ярдәм итте.

Шул ук вакытта хәл итүне таләп итә торган берничә проблема саклана.

Системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнар арасында шәһәр халкы өстенлек итә, алар күбесенчә 29 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр (2024 ел нәтиҗәләре буенча 90,8 процент). Өлкән яштәге халыкның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү дәрәҗәсе җитәрлек түгел (2024 ел нәтиҗәләре буенча 29,2 процент).

Ел саен спорт объектларын норматив хәлгә китерү мәсьәләсе тагын да актуальләшә бара.

Физик культура һәм спорт өлкәсенең инвестиция җәлеп итүчәнлеген үстерүне стимуллаштыру, шул исәптән эшмәкәрлекне һәм дәүләт-шәхси (муниципаль-шәхси) партнерлыкны үстерү кирәк.

Дәүләт федераль һәм төбәк программаларын кабул итә, адаптив спортны үстерүгә юнәлдерелгән пилот проектларны гамәлгә ашыра. Россия Федерациясенең законнар базасында инвалидлар һәм сәламәтлек торышы буенча чикләүләре булмаган кешеләрнең хокукларын тигезләүче документлар барлыкка килә. Әмма хәзерге вакытта хокукларның тигезлеге күбесенчә декларатив характерда, чөнки аларның практик гамәлгә ашырылу шартлары җитәрлек түгел, бу күп очракта Россия Федерациясе төбәкләрендә, аерым алганда Татарстан Республикасында, шулай ук муниципаль дәрәҗәдә адаптив спортны үстерү белән идарә итү проблемасының фәнни-практик эшкәртелмәгәнлеге белән бәйле.

Спортчыларны әзерләү сыйфатына таләпләрне арттыру, тармак белгечләрен әзерләү процессын үзгәртү зарурлыгын таләп итә, шул исәптән паралимпия, сурдлимпия спорт төрләре һәм акыл үсешендә кимчелекләре булган кешеләр спорты өлкәсендә, балалар организмын үсеш үзенчәлекләрен белгән, сенситив чорларны исәпкә алып, мәҗбүри әзерлексез тиешле йөкләнешләрне формалаштыручы, инвалид спортчыларны әзерләү үзенчәлекләрен, адаптив спортны гомумән белгән яңа буын тренерларын формалаштыру.

Шулай ук хәзерге вакытта спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программалары буенча укый торган, спорт разрядлары һәм исемнәре булган кешеләрнең өлеше, спорт әзерлеге программалары буенча шөгыльләнүче кешеләрнең гомуми санында 40 процентка тигез.

Югарырак күрсәткечләргә ирешү өчен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан спортчыларга һәм тренер-укытучыларга дәүләт ярдәме дәвам ителәчәк.

Муниципаль спорт оешмалары өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алуга бюджет чараларын арттыру, әлеге оешмаларда спорт төрләре буенча яңа бүлекләр ачу, спортчыларның төрле ярышларда катнашуын һәм чыгыш ясауларын оештыру, аларга спорт разрядлары бирү планлаштырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, халык саны 50 мең кешегә кадәр булган торак пунктларга эшкә килгән (күченеп килгән) тренер кадрларга һәм физик культура һәм спорт өлкәсе хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтү максатларында 2026 елдан 2028 елга кадәр «Авыл тренере» программасы кысаларында чаралар гамәлгә ашыру планлаштырыла.

Дәүләт программасын гамәлгә ашыруның төп рискларына түбәндәгеләр керә:

чараларны гамәлгә ашыруга кирәкле финанс тәэминаты булмау һәм кайбер чараларның түбән инвестиция җәлеп итүчәнлеге белән бәйле финанс рисклары;

беренче чиратта, гражданнарның керемнәр структурасындагы үзгәрешләр һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә хезмәтләргә ихтыяҗ кимү белән бәйле базар рисклары;

дәүләт программасын башкаручылар арасында үзара хезмәттәшлекнең җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле булмавы белән бәйле административ рисклар.

Дәүләт программасын уңышлы гамәлгә ашыруның иң мөһим шартлары – әлеге рискларны минимальләштерү, билгеләнгән чараларның үтәлешен нәтиҗәле мониторинглау, дәүләт программасының өстенлекле нәтиҗәләрен һәм күрсәткечләрен төзәтү буенча оператив чаралар кабул итү.

Дәүләт программасын гамәлгә ашыру 2028 елга кадәр республика халкының кимендә 66,6 процентын физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итәргә һәм сәламәт яшәү рәвешенә иярләндерергә мөмкинлек бирәчәк, бу ахыр чиктә Татарстан Республикасы гражданнарының яшәү сыйфатын яхшыртуга уңай йогынты ясаячак.

Республика спортчыларының Россия спорт мәйданында көндәшлеккә сәләте сизелерлек артачак, бу Татарстан Республикасыннан спортчыларга Россия Федерациясе җыелма командалары составында даими булырга мөмкинлек бирәчәк.

Шул ук вакытта Татарстан спортчыларының ярышлардагы уңышлары Татарстан Республикасын бу ярышларны үз территориясендә үткәрү хокукына тәкъдим итү өчен шартлар тудыра, бу икътисади потенциалны үстерүгә, туристик агымнарны арттыруга, алдынгы технологияләрне тарату һәм стимуллаштыруга, озак вакытлы инвестицияләр җәлеп итүгә ярдәм итә.»;

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте өстенлекләре һәм максатлары тасвирламасы

Физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең максатлары Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 24 ноябрендәге б-3081 номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү

стратегиясенә, 2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәрге план чорына Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча бердәм планга, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (алга таба – Стратегия-2030) туры килә.

Татарстан Республикасы физик культура һәм спорт өлкәсендә очраша торган актуаль проблемаларны бетерү, шулай ук Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең стратегик максатларына һәм бурычларына ирешү максатларында дәүләт программасы күрсәткечләренең структурасы һәм системасы билгеләнде.

1 нче максат: 2028 елга кадәр физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче гражданнар өлешен 66,6 процентка кадәр арттыру, ул 2028 елга кадәр түбәндәге күрсәткечләргә ирешү белән характерлана:

системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнар өлешен 59,8 процентка кадәр арттыру;

физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче 30 яшьтән 54 яшькә кадәрге (хатын-кызлар) һәм 59 яшькә кадәрге (ир-атлар) гражданнар, әлеге яшь категориясендәге гражданнарның гомуми санында 68,3 процентка кадәр арттыру;

әлеге яшь категориясендә гражданнарның гомуми санында физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче 55 яшьтән (хатын-кызлар) һәм 60 яшьтән (ир-атлар) 79 яшькә кадәрге гражданнар өлешен 40 процентка кадәр арттыру;

системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче 3 – 29 яшьлек гражданнар өлешен әлеге яшь категориясендәге гражданнарның гомуми санында 90,8 процентка кадәр арттыру;

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затлар һәм инвалидларның гомуми санында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен бернинди каршылыгы булмаган физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче әлеге категориядәге затлар өлешен 39,5 процентка кадәр арттыру;

гражданнарның спорт корылмалары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен, спорт объектларының бер мәртәбә үткәрү сәләтеннән чыгып, 72,7 процентка кадәр арттыру;

спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын бушлай гамәлгә ашыручы спорт учреждениеләрендә укучы балалар, шул исәптән аз керемле гаиләләрдән булган балалар өлешен 100 процентка җиткерү.

2 нче максат: Татарстан Республикасының олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия спорт төрләре буенча Россия Федерациясе җыелма командалары составына керүче Татарстан Республикасы спортчылары санын 2028 елга 970 кешегә кадәр арттыру, бу 2028 елга түбәндәге күрсәткечләргә ирешү белән характерлана:

югары класслы әзерлекле спортчылар санын 1 818 кешегә кадәр тәэмин итү;

спорт мәктәпләре, олимпия резервы спорт мәктәпләре һәм олимпия резервы училищелары системасында шөгыльләнүче затларның гомуми санында разрядлы спортчылар өлешен 40,4 процентка кадәр арттыру;

спортны камилләштерү этабында шөгыльләнүчеләрнең гомуми санында спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда югары спорт осталыгы этабында шөгыльләнүчеләр өлешен 22,5 процентка кадәр арттыру.

Әлеге программа документлары нигезендә физик культура һәм спорт үсешенең өстенлекле юнәлешләре санына түбәндәгеләр керә:

гражданнарны, иң беренче чиратта, балаларны һәм яшьләрне, физик культура һәм массакүләм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү;

халык өчен спорт объектларының, шул исәптән авыл территорияләрендә һәм авыл агломерацияләрендә, шулай ук сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр һәм инвалидлар өчен дә, мөмкинлеген арттыру;

адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерү;

спорт резервын әзерләү системасын камилләштерү;

халыкара мәйданда спортның көндәшлеккә сәләтлен арттыру.

Республика Татарстанның муниципаль районнары дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруда катнашу аның нәтиҗәлелеге өчен кирәкле шарт булып тора. Шул ук вакытта физик культура һәм спортны үстерү буенча муниципаль программалар дәүләт программасының максатларына һәм бурычларына туры килергә тиеш.»;

IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарәсе бурычлары,
аларны нәтиҗәле хәл итү ысуллары

«2028 елга кадәр физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче гражданнар өлешен 66,6 процентка кадәр арттыру» дәүләт программасы максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

гражданнарны физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру;

төрле категорияләр һәм халык төркемнәре өчен нәтиҗәле физик тәрбия системасын булдыру;

халыкның барлык категорияләр һәм төркемнәре өчен спорт инфраструктурасының мөмкинлеген арттыру;

физик культура һәм спорт өлкәсендә кадрлар резервын әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү системасын үстерү;

физик культура һәм спорт өлкәсендә норматив-хокукый көйләүне камилләштерү;

физик культура-массакүләм чараларны үткәргәндә куркынычсызлыкны тәэмин итү.

Әлеге бурычларны хәл итү дәүләт программасы кысаларында «Бизнес-спринт (Мин спортны сайлыйм)» төбәк проектында, «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» төбәк проектында, шулай ук «Физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә чаралар үткәрү» процесслы чаралары комплексында каралган чаралар системасын гамәлгә ашыру аша тәэмин ителә.

«Россия Федерациясе җыелма командалары составына керүче олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия спорт төрләре буенча Татарстан Республикасы спортчылары санын 2028 елга кадәр 970 кешегә кадәр арттыру» дәүләт программасы максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

медальләр яулау мөмкинлегенә ия булган перспектив спортчылар санын арттыруга юнәлдерелгән шартлар булдыру;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, халык саны 50 мең кешегә кадәр булган торак пунктларга эшкә килгән (күченеп килгән) физик культура һәм спорт өлкәсе хезмәткәрләре санының максатчан күрсәткеченә «Авыл тренере» программасы механизмын кулланып ирешүне тәэмин итү;

югары класслы спортчыларны әзерләү системасын камилләштерү;

югары класслы спортчыларны әзерләүнең фәнни-методик һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин ителешенең нәтиҗәлелеген арттыру;

югары класслы спортчыларны һәм спорт резервын әзерләүнең антидопинг тәэмин ителешен үстерү;

Татарстан Республикасы җыелма командалары һәм югары класслы спортчыларны әзерләү һәм чыгыш ясау өчен матди-техник һәм оештыру шартларын тәэмин итү;

Татарстан Республикасы территориясендә зур халыкара спорт ярышларын югары оештыру дәрәҗәсендә үткәрү өчен шартлар тудыру;

югары казанышлар спорты өлкәсендә норматив-хокукый көйләүне камилләштерү;

зур спорт чараларын үткәрүдә куркынычсызлыкны тәэмин итү.

Әлеге бурычларны хәл итү дәүләт программасы кысаларында «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» төбәк проектында, шулай ук «Спорт чараларын үткәрү, югары класслы спортчылар әзерләүне тәэмин итү» процесслы чаралар комплексында каралган чаралар системасын гамәлгә ашыру аша тәэмин ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин